| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ТЭРБИТ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 май 2024ел. Иске Тэрбит ав. № 9

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Иске Тэрбит авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләр өчен саналган җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислары булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычлары булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар өчен исәпләнелә торган бурыч булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлеге Советы түбәндәге карарлары үз көчен югалткан танырга:

«Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өстәмә нигезләр турында» 2022 елның 30 11 декабрендәге 15 номерлы;

«Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр турында» 2022

елның 30 декабрендәге 15 номерлы Иске Тэрбит авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 15 номерлы.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Иске Тэрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Иске Тэрбит авыл җирлеге Башлыгы В.Г.Тимофеев